**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Комыргуҗа авыл җирлеге Комыргуҗа торак пунктында**

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

“19” ноябрь 2023 ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-Фз номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегенең Комыргуҗа торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Комыргуҗа авылы территориясендә 2024 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегенең Комыргуҗа торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 1нче төркем инвалидларыннан һәм мобилизацияләнгән гражданнарның гаилә әгъзаларыннан, РФ Оборона министрлыгы белән контракт төзегән хәрби хезмәткәрләрдән һәм РФ Оборона министрлыгы белән контракт төзегән хәрби хезмәткәрләрнең гаилә әгъзаларыннан тыш 500 (биш йөз) сум сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

- Комыргуҗа авылы зиратын чистарту ( үлән чабу);
- Комыргуҗа авылында территорияне чистарту үлән чабу (эш һәм хезмәт өчен түләү);
- Комыргуҗа авылы паркы территориясендә газон чабу (эш һәм хезмәт өчен түләү);
- Комыргуҗа авылында агач кисү өчен бензопила сатып алу;
- Комыргуҗа авылында (Тукай урамына) юл салу өчен вак таш сатып алу(эш һәм хезмәт өчен түләү);
- Комыргуҗа авылы урамнарын кардан чистарту (эш һәм хезмәт өчен түләү).

3.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегенең Комыргуҗа авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Комыргуҗа авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Комыргуҗа авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Комыргуҗа авыл җирлеге башлыгы Низамиев Ф.Ф.